Минем әтием -- Туган ил сакчысы.

Минем уйлавымча, Ватанны саклау - һәрбер ир кешенең изге бурычы. Аны ата-бабаларыбыз кан-күз яшьләре бәрабәренә саклап калган. Күпме кыенлыклар кичкәннәр, әмма Ватаннарыннан ваз кичмәгәннәр, илбасарларга бирешмәгәннәр.
Минем әтием дә,бабам да машина йөртүче булып хезмәт иткәннәр.

Әтием- Заһидуллин Равил Хөснетдин улы 1968 нче елның 12 декабрендә Тәтеш районы Алабирде авылында дөньяга килә.Мәктәпне уңышлы гына тәмамлап, хәрби хезмәткә алына. Әтием 1987-1989 елларда Әзербәйҗан Республикасында урнашкан Сумгаит шәһәрендә, машина йөртүче булып хезмәт итә. Ул вакытларны искә төшергәндә:"Андагы климат бездәгегә охшамаган , ике елга бер мәртәбә кар яуды. Виноград, гранат, персик һәм инжир урамда һәр капка төбендә үсеп утыра иде,-"ди, чөнки ул һәрнәрсәнең бары тик уңай ягын гына күргән, күңелсез вакыйгаларны искә төшерергә яратмый. Хәрби бурычын үтәп кайткач, Казан институтларының берсендә мал табибы һөнәрен үзләштерә.Хәзер һәвәскәр умартачы. Әтием мине һәм кечкенә сеңлем Алияне бик ярата, шукланып китсәк тә, безгә тавыш күтәрми. Кирәк вакытта кырыс та була белә, чөнки мин аның кушкан эшләрен һәрвакыт үтәргә тырышам.Ул мине авырлыкларга түзәргә өйрәтә.Ә аның өчен чаңгыда, тимераякта шуарга кирәк,-ди әтием. Үзеңне төрле яктан әзерләргә кирәк.Организмны чыныктыру өчен төрле физик күнекмәләр ясарга, чыныгу өчен салкын су белән юынырга кирәк.Зур үскәч, әтием кебек армия сафларына барырга, ил алдындагы изге бурычымны үтәргә телим.Әтием белән мин бик горурланам, аны якынлашып килүче Ватанны саклаучылар бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм. Аңа саулык- сәламәтлек, озын гомер һәм җан тынычлыгы телим.

Илдар Заһидуллин, 4 сыйныф укучысы.